Балалар саклау көненә багышлана

Татар сандугачы

Хөрмәтле татар укучыларыбыз! Безнең бүгенге «Авылым тавышлары» чыгышында 1 июнь аеның балалар көненә багышлаган мәкаләсен бастырып чыгарабыз. Бу мәкаләдә яшь сәләт иясе Ирек Хусаинов турында сүз барыр. Ләмберә беренче мәктәбенең укучысы, ул авылдашлары белән яратылган жырчы да, бишлеләргә генә укучы да, спортсмен да, — бер сүз белән әйткәндә, төрле яктан уңган мәктәп баласы.

Ирекнең туган авылы — Ләмберә. Хәзер дә ул әни—әтисе һәм дүрт яшьлек бертуганы Динар белән — чәчәктәй Ләберәбезнең уртасында яши. Бала чагыннан ук, укытучыларының сүзләре буенча, Ирек бик кешелекле һәм ярдәмчел үсеп килә торган була. Хәзер бу ир бала алтынчы сыйныфта укый. Сыйныф җитәкчесе Э.А. Фетхуллова Ирекне тәре көмеш белән чагыштыра, бик укыган һәм кызыксынучан малай, ди. Үзенең актив катнашуы белән дәресләрне җанландыра. Татар телен белә, сөйләшә, үзенең сөйләшендә саф татар сүзләрен кулланырга тырыша. Кечкенә сыйныфларда сәнгатьле уку ярышларына катнаша. Татар язучыларның юбилейларына багышланган ярышларда беренче урыннар - аныкы.

Ирек Хусаинов балалар сәнгать мәктәбендә дә укый. Дүрт ел буе яшь укытучысы Ләйсан Айса кызы Байбикова җитәкчелегендә татар җырларының осталыгын, милли көйләрнең матурлыгын тырышып, зур көч биреп, өйрәнә. Бу өлкәдә Ирек бик зур уңышларга ирешә. Җыр—музыкаль, район яки республика күләмендәге, ярышларда җиңүче. Ләмберә сәхнәсендә дә, республиканың зур сәхнәләрендә дә, Ирек Хусаинов татар моңнарын, татар көйләрен тыңлаучыларның күңелләрен сокландырып һәм хисләндереп җырлый. Мәктәп һәм авылда уздырыла торган әдәби—музыкаль кичәләрнең алмаштыргысыз җырчысы. Ләмберә районының «Авылым тавышлары» дигән ачык татар җыры ярышында Ирек үз яшьлекләре арасында беренче урынны яулады, халык иҗаты «Шумбрат, Мордовия!» фестивалендә да актив катнашучы.

Эшне сөючән Ирек әтисе Назыл Фаннур улына һәм әнисе Лариса Искандәр кызына өй хуҗалыгында беренче ярдәмче: кечкенә бертуган сабый Динарын да яныннан калдырмый, бакчада ындырда да булыша. «Кемнән синдә җырга осталык туган?» сорауга Ирек шунды җавап бирдә: «Минем әнием яшьлегендә бик матур җырчы иде, музыкаль мәктәпне дә бетерде, хәзер дә бик яхшы җырлый. Әтием үзе җырламаса да, татар җырларын тыңларга бик ярата — тик популяр Салаватның көйләрен тыңлый. Ә мин халык яраткан җырларны сөям — «Аерылмагыз», «Ай, былбылым» — күңелемә бик тулалар! Әле укытучым белән өйрәнгән «Туган авылым» җырын бик яратам. Бу җыр Татарстан җырчысы Зөлфиә Минһава репертуарыннан. Ә җәен Искәндәр бабакам белән печәнгә барганда, юл буе татар җырлары җырлый киләбез. Арбага тиялгән печәннең иң югарысына менеп утырабыз да, бабам татар көен сузып җибәрә, ә мин инде аңа кушылып, кабатлыйм...».

«Татарча бик матур итеп сөйлисең, — дидем мин Иреккә, — кайдан синдә мондый белем, оста сөйләшү?» Моңа малай шулай диде: «Укытучыма Наилә Якуп кызы Усмановага рәхмәт — аның дәресләрендә күп нәрсәгә без өйрәнәбез. Ул безне татар язучылары иҗаты белән таныштыра һәм аларның әсәрләрен аңларга өйрәтә. Аның тырышлыгы белән, мин Тукай, Җәлил, Такташ, Камал һәм башка танылган татар әдәбияты классиклары әсәрләрен белә башладым. Мәсәлән, миңа Муса Җәлилнең «Кызыл ромашка» шигыре бик ошады, күңелемә тулды. Анда яраланган солдат каны ромашкага тиеп, кызарткан... Мин өйдә әнием—әтием, әби—бабаларым белән дә гел татарча сөйләшәм. Ләмберәдәге Гөлсирә әбием белән күпкә җиңелерәк сөйләргә, чөнки ул безнең «мишәр» диалектында аралаша. Ә Ульян өлкәсендә яши торган әтинең әнисе — Гөлйөзем әбием белән миңа сөйләшергә авырырак, ул «казанча», әдәби телгә якынырак сөйләшә».

Китапханә көненә багышлана

Китапханәче — акыл хазинәсе

Майның 27 көнендә Россиядә Китапханәләр көне уза. Моңа мәкаләбез дә багышланган. Районыбызның китапханәләрендә һөнәрле хезмәтчеләр эшли. Аларның берсе — Ләмберә урта балалар китапханәсенең хезмәтчесе, Рәйсә Каюм кызы Биктякова. Ул сөйгән эшенә, бөтен күңелен—җанын биреп, гомеренең 33 елын багышлады. Ә балалар белән 25 ел буе инде эшли.

Рәйсә Каюм кызы Биктякова 2 ноябрьнең 1956-ичы елында Ләмберәнең Батрак урамында алты балалы гаиләдә туды. Бертуганнары арасында ул уртанчы кыз иде. Тәүфикле, эшчән ана—ата белән Рәйсә үзе дә тәртипле, эшне сөючән, акыллы кеше булып үсте.

Аның әтисе Каюм Файзулла улы Бөек Ватан сугыш ветераны, зур сугышлар узды, авыр күремнәр күрде. Унҗиде яшендә фронтка китеп, 1947-иче елны гына кайтты. Бервакыт туган өенә «улыгыз үлгән» дигән хәбәр килде. — Гаиләсе сөйгән уллары белән мәңгегә саубуллашып өлгерде... Һәм берничә вакыттан соң, көтмәгәндә, төнне Каюм өенең ишеген шакады. Өйдәгеләр, куркынышып, нәри диеп мени, «безнең Каюм күптән үлгән инде» диеп, ишекне ачмадылар. Туры килде батыр егетке күршеләргә шакырырга — алар каршыладылар. Соңыннан Каюм гаиләсен куандырып, исләрен китәрәп, өенә кайтты...

Тормышын төзи башлады. Чирмеш кызы Максутова Зәкиә Ибрагим кызына өйләнде. Батрак урамында өй салды. Балалар бер бер атлы, өлгергән җимешләр кебек, туып килде. Каюм абый, бөтен саулыгын сугыш кырларында югалтып, берниндя эшкә ярамады. Шулай, өй хуҗасы булып, тирәсендә, өендә мавыкты. Әниләренең иңнәренә күп авырлык төште — гомере буе авыр җиештыручы эшендә дә хезмәт итте, балаларын да асырады, гаиләне дә тота белде. Әти—әниләрен балалары бигрәк тә кадерләп, бөтен кайнар күңелләре белән ярата иде. Алар бит ашатып—киендереп кенә түгел, ә туры дөрес тормыш юлына юнәлдерүчеләр. Укуның кирәклеген һәм әһәмиятлеген аңлатып калдырдылар гомерлеккә. Рәйсәнең сүзе буенча, ул нәкъ әнисенең тырышлыгы ярдәмендә, китап укуына бөтен күңеле белән бирелгәне, китап аңлавы өчен рәхмәтле. Зәкиә апа шундый авыр хезмәтләр арасында, утырып китаплар укырга вакыт таба иде! Шуның турында кызы Рәйсә исе китеп, безгә әйтте: «Әле «җиңел» әдәбият түгел, ә җитди, мөһим китаплар укый иде — Достоевскийны, Тургеневны, Толстойны, Чеховны... Һәм шулай әйтә иде безгә: «Мондый әдәбият, бу язучыларның әсәрләре — мәңгелекләр... Кирәкмәгән җиңел—җилпе язмалар бер сәгатьтә ук онытыла, ә болар гомерлеккә якты нурлар сибеп торалар...»

Рәйсә Каюм кызына яшьлектән ук, гомере буе яхшы кешеләр генә очрый. Шуларның арасында укытучыларын Бәриза Хайрулла кызы Грошеваны, Вера Никифор кызы Мартыноваңы, Сания Садыйк кызы Усмановаңы ул хөрмәтләп искә ала. Мәктәпне тәмамлагач, Рәйсә Каюм кызы автоматик—санау бүлегенә эшкә керде. Эше түләүле, ләкин күңеленә тулмады. Шуңа күрә, Рәйсә апабыз мәдәният уку йортын тәмамлап, китапханәче хезмәтен үти башлады. Бу юл буенда ул инде утыз эч ел атлый. 1981-нче елны китапханәдә китаплар төзәтү бүлегендә, Сәйдә Садыйк кызы Кантеева җитәкчелегендә, эшли башлады. Соңыннан китапханәнең уку залына күчте. Ә инде 1989-ычы елдан бирле балалар китапханәсендә бүгенгә кадәр бик әйбәт кенә, бары хисен, йөрәген биреп эшли. Һәрбер баланы ул куанып, кочаклап каршы ала. Күпме кичәләр, ярышлар уздыра мәктәп балалары өчен! Ләкин иң мөһиме аның — китаплар илендә балалар өчен оста, белемле китапханәче булырга.

Рәйсә Каюм кызы Биктякова турында яшьтәше Наилә Якуп кызы Усманова болай ди:

— Мин Рәйсә Каюм кызын күптән беләм. Без аның белән бер мәктәптә укыдык. Гомер буе ул тәртипле һәм кешелекле, гадел. Теләсә нинди сорауга җавап бирә, булыша, теләсә нинди китапны табып китерә. Үзе бик торышчан, тыңгы белми торган, эшендә генә түгел, ә гаиләсендә, хуҗалыгында да, балалары өчен дә җанын бирергә анык. Ире белән дус—тату тора, дәүләте өчен янып йөри. Ә үзенең һөнәрен ул тептән белә. Һәрбер китапның нәрсә турында икәнен генә түгел, битенә хәтле белә. Чын китапханәче укымышлы кеше булырга тиеш. — Рәйсә ханымыбыз шундый.

Авылым тавышлары

Выпуск №47

Мәкаләләр

Бал татлы, балдан бала татлы, баладан йокы татлы.

Берәүләргә көн бәйрәм, көн дә туй, — берәүләргә көн дә сагыш, көн дә уй.

Булдыклы кеше таштан икмәк чыгарыр.

Дөньяда иң кызганыч — эшкә ялкау кеше.

Белгән белгәнен эшләр, белмәгән бармагын тешләр.

Һөнәр иясе бай булмас, бай булмаса да ач булмас.

Җырлыйк әле бергәләп

Равил Каюмов көе һәм сүзләре

Бала сагышы

Гомер бүләк иттең, ләкин балачагым
Ак биләүдәй назлап төрмәдең.
«Балам» дигән сүзен тилмереп лә көттем,
Елап чыга идем төннәрен.

Ташлап киттең, әнкәй,
Ятим итеп, әнкәй,
Ничек түзә синең йөрәгең?

Сине кайтаруны сорап ялвардым мин
Ал таңнардан, ачы җилләрдән.
Нәүмиз, ятим иттең батырь кисәгеңне
«Әни» дигән назлы сүзләрдән.

Өзгәләнә булыр хәзер үзәкләрең,
Күргәч улың — лачын егетне.
Ятимлекнең ачы тамчылары юды
Сиңа булган соңгы өметне.

Хәбәрләр

Гөрли сабантуйлар

...БЕЗНЕҢ РАЙОНДА

Ләмберә районыбызның Администрация оештырма комитеты, Татар мәдәният үзәге, мәдәният җитәкчелеге һәм бөтен иҗат төркемнәр, коллективлар киләчәк, майның 31 көнендә узачак, Республикабызның X-нче милли-мәдәният Сабан туена аныкланалар. Район мәдәният бүлегенең җитәкчесе Шамиль Али улы Курмакаев безнең сорауларга җавап бирде. Быел хөрмәтле бәйрәм кунакларыбыз Татарстанның Апас ягыннан килерләр. Шул делегациядә — Апас районының җитәкчеләре, бизнесменнар, танылган җырчы—биючеләр, спортменнар һәм башкалары. Тагын берничә күрше өлкәләрдән: Ульян, Пензә, Нижгәр якларыннан — кунаклар көтелә. Сабан туебызда күңеллек, яктылык, кунакчыллык, җыр-бию генә түгел, ә бик күп сы—хөрмәт, авылларыбызның күргәзмәләре, бәйрәм ярминкәсе һәм башка кызыклы һәм куанычлы нәрсәләр булачак. Тулырак киләсе Сабан туе турында газетабызның шушы һәм чираттагы чыгышларында рус телендә укыгыз.

...КУНАКЛАРДА

Безнең район делегациясе Волгоград өлкәсенең Малые Чапурники авылында уза торган Бөтенроссия авыл Сабан туена да барачак. 24 маенда республикабызны бу Сабантуй бәйрәмендә зур делегация тәкъдим итәр. Делегация әгъзалары арасында Ләмберә районының җырчылары, Татар мәдәният үзәгенең методисты Алсу Сюбаева, республиканың атказанган мәдәният хезмәткәре, бию «Калейдоскоп» төркеменең җитәкчесе Лариса Ванина һәм башкалар. Аларның кунак итеп барып кайтулары турында киләсе чыгышларда укыгыз.

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШ

Атнага бер мәртәбә төрле үләннәрдән битлек ясау файдалы булыр. Аны болай әзерлиләр: икешәр аш кашыгы кипкән ромашка, юкә чәчәге, миләүшә һәм бер аш кашыгы шалфей алалар. Боларның барысын бергә кушып, ваклап төярге кирәк. Аннары куе ботка барлыкка килгәнче өстенә кайнар су агызасың. Бер минутка өстен каплап торасың һәм битлекне җылы килеш биткә, муенга сөртәсең. Моңа агач кәрәкчек белән сыласаң, тагы да яхшы булыр. Соңыннан марля белән каплыйсың да, 20 минут ятып торасың. Күзләргә шалфей төнәтмәсенә яки чәйгә манылган мамык куеп торырга кирәк.

Полосаны оештырды Умида Яхина.